ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО БИОЛОГИЧЕСКИМ РЕСУРСАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ БИОЛОГИК РЕСУРСЛАР БУЕНЧА ДӘУЛӘТ КОМИТЕТЫ

---

**Приказ** **Боерык**

09.10.2019 г. Казань № 304-од

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында дәүләт хезмәткәрен коррупциячел хокук бозуларга этәрү максатыннан кылынган мөрәҗәгать очраклары турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә хәбәр бирү тәртибе хакында

“Коррупциягә каршы көрәш турында” 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 5 өлеше нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында дәүләт хезмәткәрен коррупциячел хокук бозуларга этәрү максатыннан кылынган мөрәҗәгать очраклары турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә хәбәр бирү тәртибен расларга.
2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары Ю.Б. Матвеевка тапшырырга.

Рәис Ф.С.Батков

Татарстан Республикасы
Биологик ресурслар буенча
дәүләт комитетының 2019
елның 9 октябрендәге 304-од
номерлы боерыгына кушымта

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында дәүләт хезмәткәрен коррупциячел хокук бозуларга этәрү максатыннан кылынган мөрәҗәгать очраклары турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә хәбәр бирү тәртибе.

1. Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында дәүләт хезмәткәрен коррупциячел хокук бозуларга этәрү максатыннан кылынган мөрәҗәгать очраклары турында яллаучы вәкиленә хәбәр бирү тәртибе (алга таба – Тәртип) «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы 5 бүлеге нигезендә эшләнде.

Тәртип Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан (алга таба - гражданлык хезмәткәрләре, Дәүләт комитеты), аларны коррупциячел хокук бозуларга этәрү максатыннан мөрәҗәгать итү факты турында, яллаучының вәкиле булып торган Дәүләт комитеты рәисенә (алга таба - Рәис) хәбәр итү процедурасын регламентлаштыра.

2. Коррупциячел хокук бозуларга этәрү максатыннан мөрәҗәгать итү фактлары турында хәбәр итү (әлеге фактлар буенча тикшерү үткәрелә торган яки үткәрелгән очраклардан тыш) граждан хезмәткәренең вазыйфаи (хезмәт) бурычы булып тора.

3. Коррупциячел хокук бозуларга этәрү максатыннан мөрәҗәгать итү фактлары турында яллаучы вәкиленә хәбәр итү (алга таба – Хәбәрнамә), Тәртипнең 1нче кушымтасы нигезендә, граждан хезмәткәре тарафыннан язмача төзелә.

Хәбәрнамәдә түбәндәге мәгълүмат чагылырга тиеш:

хәбәрнамәне җибәргән затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазифасы һәм структур бүлекчәсе, яшәү урыны һәм телефоны;

коррупциячел хокук бозуларга этәрү максатыннан нинди дә булса затларның, хезмәт вазыйфаларын үтәүгә бәйле рәвештә, Дәүләт комитетының граждан хезмәткәренә мөрәҗәгать итү факты (билгеле булган очраклары) булган хәлләрнең тасвирламасы (датасы, урыны, вакыты, башка шартлар);

коррупциячел хокук бозуга этәрү турында раслаучы, граждан хезмәткәренә кергән мөрәҗәгатьнең (башка зат тарафыннан хезмәткәргә карата башкарылган гамәлләр, тәкъдимнәр, гаризалар, таләпләр, мөрәҗәгатьләр) җентекле тасвирламасы, шулай ук аларны кылуга этәрә торган коррупциячел хокук бозу билгеләре булган гамәлләр тасвирламасы;

коррупциячел хокук бозуларга тартучы физик (юридик) зат турында барлык мәгълүматлар;

коррупциячел хокук бозуларга тартылу чарасы һәм шартлары (акча бирү, янау, алдау һ. б.), шулай ук коррупциячел хокук бозуларга этәрү турында затның тәкъдимен кабул итүдән баш тарту (килешү) турында мәгълүмат;

хәбәрнамәне прокуратура органнарына яисә башка дәүләт органнарына җибәрү датасы (нинди).

Хәбәрнамәгә граждан хезмәткәрен коррупцион хокук бозуга этәрү максатыннан нинди дә булса затларның мөрәҗәгать итү шартларын раслаучы барлык материаллар теркәлә.

4. Хәбәрнамә рәис ( аның вазыйфаларын башкаручы зат) исеменә языла һәм коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы затка (алга таба - Җаваплы зат) кичекмәстән тапшырыла, ә әгәр әлеге тәкъдим эш вакытыннан тыш керсә, хәбәрнамә хезмәт итү урынына килеп җитүгә үк кичекмәстән языла.

Граждан хезмәткәре вазыйфаи (хезмәт) бурычларын үтәмәгәндә яисә даими хезмәт итү урыныннан читтә булганда, Хәбәрнамә почта аша, факсимиль элемтә каналлары яисә электрон элемтәнең башка каналлары аша җибәрелергә мөмкин. Хезмәткә әйләнеп кайткач Хәбәрнамә оригиналы Җаваплы затка тапшырыла.

5. Җаваплы зат Хәбәрнамәне, Тәртипнең 2 нче кушымтасы нигезендәге форма буенча, дәүләт хезмәткәрен коррупциячел хокук бозуларга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турындагы хәбәрнамәләрне теркәү журналында (алга таба-Журнал) терки.

6. Хәбәрнамәне теркәгәннән соң, граждан хезмәткәренә Журналда хәбәрнамәне кабул иткән зат турындагы белешмәләрне һәм аны теркәү датасын күрсәтеп, Хәбәрнамә күчермәсе имза астында бирелә. Хәбәрнамә почта аша килгән очракта, Хәбәрнамәнең күчермәсе почта аша заказлы хат белән мөрәҗәгать иткән граждан хезмәткәренә җибәрелә.

Хәбәрнамәне теркәүдән баш тарту, шулай ук Хәбәрнамәнең күчермәсен бирмәү рөхсәт ителми.

Алынган мәгълүматларның конфиденциальлеге «Персональ мәгълүматлар турында»2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә тәэмин ителә.

7. Хәбәрнамәне теркәгән көнне Җаваплы зат аны, эчке эшләр органнарына яисә башка дәүләт органнарына җибәрү турында карар кабул итү өчен, рәискә (аның вазыйфаларын башкаручы затка) карап тикшерүгә тапшыра.

8. Рәис (аның вазыйфаларын башкаручы зат) тарафыннан Хәбәрнамәне эчке эшләр органнарына яисә башка дәүләт органнарына җибәрү турында карар кабул ителгәндә, Җаваплы зат, мондый карар кабул ителгән көннән соң ике эш көненнән дә соңга калмыйча, материалларны кушып, Хәбәрнамәне җибәрә.

9. Яллаучы вәкиленә, прокуратура органнарына яисә башка дәүләт органнарына коррупциячел хокук бозуга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында хәбәр иткән граждан хезмәткәре Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт яклавында тора.

10. «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә, Дәүләт комитетындагы

граждан хезмәткәрләре тарафыннан коррупциячел хокук бозуга этәрү фактлары турында эшкә алучы вәкиленә хәбәр итү бурычын үтәмәү, аны дәүләт хезмәтеннән азат итү яки Россия Федерациясе законнары нигезендә башка төр җаваплылыкка тарта торган хокук бозу булып тора.

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында дәүләт хезмәткәрен коррупциячел хокук бозуларга этәрү максатыннан кылынган мөрәҗәгать очраклары турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә хәбәр бирү Тәртибенә 1нче кушымта

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты рәисе
______________________________
(Ф.И.О.)
___________________________
(Ф.И.О., вазыйфа, телефон)

Коррупциячел хокук бозуларга этәрү максатыннан кылынган мөрәҗәгать очраклары турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә хәбәрнамә.

1. ______________________________________________________________
(хокук бозуга этәрүче физик затның ф. и. о., вазыйфасы, барлык мәгълүматлар күрсәтелә)
тарафыннан мине коррупциячел хокук бозуга этәрү максатыннан мөрәҗәгать итү очрагы турында хәбәр итәм(алга таба - хокук бозуга этәрү)

2. Хокук бозуга этәрү минем тарафтан
_________________________________________________________________
(уйлаган хокук бозуның асылы күрсәтелә)
эшләү максаты белән башкарылды.

3. Хокук бозуга этәрү
_________________________________________________________________
(акча бирү, янау, алдау һ. б.)
чарасы ярдәмендә башкарылды.

4. Хокук бозуга этәрү __ с. __ м., «__» ______________20__ елны ____________________________________________________________ булды.
(шәһәр, адрес)

5. Хокук бозуга этәрү киләсе шартлар нигезендә гамәлгә ашырылды:
_________________________________________________________________
_________________________________________________________________
(этәрү шартлары: телефоннан сөйләшү, шәхси очрашу, почта һ. б.)

___________________________ ____________________
(хабәрнамәне тутыру датасы) (имза)

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында дәүләт хезмәткәрен коррупциячел хокук бозуларга этәрү максатыннан кылынган мөрәҗәгать очраклары турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә хәбәр бирү Тәртибенә 2нче кушымта

Дәүләт хезмәткәрен коррупциячел хокук бозуларга этәрү максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турындагы хәбәрнамәләрне теркәү журналы

| № | Дата | Ф.И.О., хәбәрнамә биргән затның вазыйфасы | Хәбәрнамә биргән затның имзасы | Теркәүченең Ф.И.О. | Теркәүченең имзасы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |